| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзү турында**

2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру максатларында **карар бирәм:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты төзергә.

2. 2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Татарстан Республикасы Президентының «2021 елны Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итү турында» 2020 елның 5 октябрендәге ПУ-653 номерлы Указының 2 пункты икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 15 декабрь
№ ПУ-841

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 15 » декабрендәге
ПУ- 841 номерлы Указына
1 нче кушымта

**2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты (алга таба – Республика оештыру комитеты) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары), оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең 2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру вакытында үзара хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән коллегиаль орган булып тора.

2. Республика оештыру комитеты үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм аның башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Республика оештыру комитетының төп бурычлары

3. Республика оештыру комитетының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча төп чаралар планын (алга таба – төп чаралар планы) формалаштыру буенча тәкъдимнәр эшләү;

2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру белән бәйле планнарны, программаларны һәм аерым чараларны гамәлгә ашыруның барышына анализ ясау, төп чаралар планын үтәүгә һәм аны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчаның максатчан файдалануына контрольне тәэмин итү;

төп чаралар планын үтәү белән бәйле бурычларны хәл иткәндә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренең Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларны тормышка ашыру барышында үзара хезмәттәшлеген оештыру буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү.

4. Республика оештыру комитеты үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләреннән Республика комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар соратып алырга;

Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзергә;

үз утырышларына билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм башка кызыксынган затларны чакырырга;

2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## III. Республика оештыру комитеты составы

5. Республика оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

6. Республика оештыру комитеты составына аның рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм Республика оештыру комитеты эшендә җәмәгать башлангычларында катнашучы башка әгъзалары керә.

7. Республика оештыру комитеты рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты тора.

8. Республика оештыру комитеты рәисе:

Республика оештыру комитеты эшчәнлегенә җитәкчелек итә, Республика оештыру комитеты утырышларында карала торган мәсьәләләрнең исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

урынбасарлары һәм Республика оештыру комитеты әгъзалары арасында бурычларны бүлә;

утырышларның көн тәртибен, аларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

утырыш беркетмәләрен раслый һәм Республика оештыру комитетының башка документларына кул куя.

9. Республика оештыру комитеты секретаре функцияләрен Республика оештыру комитеты рәисе карары буенча аның урынбасарларының берсе башкара.

10. Республика оештыру комитеты секретаре:

Республика оештыру комитеты эшчәнлеген оештыруны, шул исәптән Республика оештыру комитеты утырышлары беркетмәләре проектын формалаштыруны, Республика оештыру комитеты әгъзаларына утырышны уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәр итүне, аларга утырышның көн тәртибен һәм материалларны җибәрүне тәэмин итә;

утырыш беркетмәләренә кул куя һәм Республика оештыру комитетының башка документларын әзерләү өчен җавап бирә.

11. Республика оештыру комитеты әгъзалары:

Республика оештыру комитеты утырышында шәхсән катнаша;

Республика оештыру комитеты компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга куя;

Республика оештыру комитеты карап тикшерә торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;

Республика оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү, аларның үтәлешенә контрольлек итү буенча кирәкле чараларны башкара.

## IV. Республика оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

12. Республика оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен уздырыла.

13. Республика оештыру комитеты утырышы материаллары Республика оештыру комитеты секретарена утырыш билгеләнгән датадан 15 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылырга тиеш. Килгән материаллар нигезендә секретарь Республика оештыру комитеты утырышының көн тәртибе проектын әзерли һәм аны утырыш уздырыласы көнгә кадәр 12 эш көненнән дә соңга калмыйча, Республика оештыру комитеты рәисенә раслауга кертә.

14. Утырышның көн тәртибе Республика оештыру комитеты рәисе тарафыннан раслана. Утырышның көн тәртибе расланганнан соң аңа үзгәрешләр кертү бары тик Республика оештыру комитеты рәисе карары белән генә мөмкин була. Бу очракта Республика оештыру комитеты секретаре Республика оештыру комитеты рәисе күрсәтмәсе буенча утырышның көн тәртибенә үзгәрешләр кертә һәм бу хакта Республика оештыру комитеты әгъзаларына хәбәр итә.

15. Республика оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

16. Республика оештыру комитеты әгъзалары утырышларда шәхсән катнаша. Республика оештыру комитеты әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, карап тикшерелә торган мәсьәләләр турында фикерен язма рәвештә тапшырырга хокуклы.

17. Республика оештыру комитеты утырышлары, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, гамәлгә хокуклы санала. Әгәр утырышта катнашучы әгъзаларының ким дигәндә яртысы Республика оештыру комитеты карарын хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала. Республика оештыру комитеты утырышларында көн тәртибе мәсьәләләрен карап тикшерү һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул ителә. Республика оештыру комитеты утырышы беркетмәсенә Республика оештыру комитеты секретаре тарафыннан кул куела һәм ул утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана.

18. Республика оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарлар агымдагы эшчәнлекләрен башкарганда аларга нигезләнеп эш итү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләренә, башка кызыксынган затларга җибәрелә.

## V. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

19. Республика оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының тиешле структур бүлекчәләре тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 15 » декабрендәге
ПУ- 841 номерлы Указына
2 нче кушымта

**2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын әзерләү һәм уздыру буенча республика оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Республика оештыру комитеты рәисе |
| Мөхәммәтшин Фәрит Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Шәйхразиев Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Республика оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Александровская Ирина Алексеевна | Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе идарәсе рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Әхмәдиева Роза Шәйхәйдәр кызы | Казан дәүләт мәдәният институты ректоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Әхмәтов<br>Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бикчәнтәев<br>Фәрит Рәфкать улы | Россия Федерациясе Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте) бүлекчәсе – Татарстан Республикасы Театр эшлеклеләре берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиева<br>Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Вахитов<br>Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Габдрахманова<br>Гөлнара Зәкәрия кызы | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Габдрахманова<br>Гөлнара Фоат кызы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институтының этнологик тикшеренүләр бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Гафуров<br>Илшат Рәфкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры, Татарстан Республикасы югары уку йортлары ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Герасимов<br>Андрей Сергеевич | Татарстан Республикасы удмурт милли-мәдәни мохтарияте идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Гыйльманов<br>Рафаил Вәли улы | Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре |
| Гыйльметдинов<br>Илдар Ирек улы | Федераль татар милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисенең беренче урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Горелик Ицхак | Татарстан Республикасының баш раввины (килешү буенча) |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Евфимий (Дубинов Евгений Евгеньевич) | Рус Православие Иске йола Чиркәвенең Казан-Нократ һәм Урал епископы (килешү буенча) |
| Егоров Иван Михайлович | Татарстан Республикасының керәшен иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Җамалетдинов Рәдиф Рифкать улы | Казан (Идел буе) федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры (килешү буенча) |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Кадыйров Тимур Рәфкать улы | Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясе советы рәисе (килешү буенча) |
| Кәлимуллин Рәшит Фәһим улы | Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Кирилл (Наконечный Михаил Васильевич) | Казан һәм Татарстан митрополиты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мәһдиев<br>Наил Гамбәр улы | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнуллин<br>Ким Мөгаллим улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры (килешү буенча) |
| Мусихина<br>Людмила Ивановна | Казан шәһәренең мари милли-мәдәни мохтарияте рәисе (килешү буенча) |
| Низамова<br>Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Нигъмәтуллина<br>Гөлшат Рәдиф кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы |
| Осокин<br>Денис Сергеевич | язучы, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (килешү буенча) |
| Сабитова<br>Наталья Михайловна | Татарстан Республикасының мордва милли-мәдәни мохтарияте рәисе (килешү буенча) |
| Сабурская<br>Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Сәлахов<br>Мәкъзүм Хәлимулла улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Салихов<br>Данил Хәбибрахман улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Салихов Радик Рим улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры (килешү буенча) |
| Самаренкин Дмитрий Анатольевич | Татарстан Республикасында чуваш милли-мәдәни мохтарияте советы рәисе (килешү буенча) |
| Сәмигуллин Камил хәзрәт (Сәмигуллин Камил Искәндәр улы) | Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие (килешү буенча) |
| Славутский Александр Яковлевич | В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры сәнгать җитәкчесе – директоры (килешү буенча) |
| Андрей Старцев (Старцев Юрий Владимирович) | Казан шәһәрендә Рим-католик чиркәвенең Воздвижение Святого Креста приходы настоятеле (килешү буенча) |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Фәйзрахманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасының Казначылык департаменты директоры |
| Фәйзуллин Равил Габдрахман улы | Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (килешү буенча) |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |

| | |
|---|---|
| Харисов<br>Ренат Мөгъсүм улы | Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (килешү буенча) |
| Хәсәнов<br>Гали Әхтәр улы | Татарстан Республикасы башкорт милли-мәдәни мохтарияте – башкортлар корылтае (конгрессы) рәисе (килешү буенча) |
| Хохорин<br>Артём Валерьевич | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры (килешү буенча) |
| Хухунашвили<br>Маринэ Мануиловна | Казан шәһәренең «Сиони» грузин милли-мәдәни мохтарияте идарәсе рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Шакиров<br>Данис Фәнис улы | Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәмсетдинов<br>Айдар Илдар улы | Казан шәһәренең «Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» полилингваль комплексы директоры (килешү буенча) |
| Шәрипов<br>Ирек Илдус улы | Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты директоры (килешү буенча) |
| Шиһабиев<br>Альберт Хазинур улы | Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Ягъфәров<br>Илдар Рәшит улы | Россия Федерациясе Кинематографиячеләр берлеге бүлекчәсе – Татарстан Республикасы Кинематографиячеләр берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Яковлев<br>Константин Геннадиевич | Татарстан халыклары ассамблеясе советы Башкарма комитеты җитәкчесе – Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |

______________